ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет Старокамкинского
сельского поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422897, ТР, Әлки районы,
Иске Камка авылы, Түбән урамы,1
йорт
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский
район, с. Старое Камкино, ул.Нижняя. д.1
тел./факс 8(84346) 73-524

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Камка авылы **КАРАР**

2021 елның 13 апреле 8№

**Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге территориясендә торак секторда һәм кешеләр күп була торган объектларда янгын-профилактика эшләрен оештыру турында**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"131-ФЗ номерлы, 1994 елның 21 декабрендәге “Янгын куркынычсызлыгы турында" 69-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге чикләрендә торак секторда һәм кешеләр күп була торган объектларда янгын-профилактика эшен оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге чикләрендә торак секторда һәм кешеләр күп була торган объектларда

янгын-профилактика эшен активлаштыру буенча чаралар планын расларга.

3. Янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү өчен хуҗалык итүче субъектларның җитәкчеләрен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы Иске Камка

авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Ә.Акберов

Әлки муниципаль районы Иске
Камкаавыл җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 13
апрелендәге 8 номерлы карарына

1 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге чикләрендә торак секторда һәм кешеләр күп була торган объектларда янгын-профилактика эшен оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм халыкны укыту тәртибе турында Нигезләмә янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү максатларын, бурычларын, тәртибен һәм чиратлылыгын билгели.

2. Янгын куркынычсызлыгы чараларына халыкны укытуның һәм янгынга каршы пропаганда уздыруның төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) янгыннарның санын һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметү;

2) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә халыкның белемнәрен камилләштерү.

3. Халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү һәм янгынга каршы пропаганда үткәрү өлкәсендәге төп бурычлар булып тора:

1)янгынны булдырмый калу, янгын чыкканда хәрәкәт итү тәртибе, янгын сүндерүнең беренчел чараларын куллану алымнарын өйрәнүгә юнәлтелгән чараларны оештыру һәм уздыру буенча халыкның белемнәрен һәм күнекмәләрен камилләштерү;

2) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге, оешмалар һәм халыкның үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

3) янгынга каршы пропаганда рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү;

4) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә халыкка оператив мәгълүмат җиткерү;

5) янгыннарны кисәтү һәм сүндерү, шулай ук халыкның янгыннарга каршы көрәштә катнашуын ирекле нигездә гражданнарны җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Янгын куркынычсызлыгы чаралары - янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, шул исәптән янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү буенча гамәлләр.

Янгыннарны профилактикалау - янгыннар килеп чыгу мөмкинлеген булдырмауга һәм аларның нәтиҗәләрен чикләүгә юнәлдерелгән превентив чаралар җыелмасы;

Янгынга каршы пропаганда - массакүләм мәгълүмат чаралары, махсус әдәбият һәм реклама продукциясен бастыру һәм тарату, халыкка мәгълүмат җиткерүнең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка рәвешләрен кулланып, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр оештырып җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү.

## II. Янгынга каршы пропаганда оештыру

1. Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге администрациясе янгынга каршы пропаганда үткәрә:

1) халык арасында янгынга каршы белешмәлекләр, листовкалар әзерләү һәм тарату;

2) янгын куркынычсызлыгы буенча социаль реклама әзерләү һәм урнаштыру;

3) янгынга каршы тематикага конкурслар, күргәзмәләр, ярышлар оештыру;

4) массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итү;

5) Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге сайтында янгынга каршы тематикага мәгълүмат урнаштыру.

Учреждениеләргә янгынга каршы пропаганда үткәрергә киңәш итеlә:

1) оешма хезмәткәрләре арасында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында белешмәлекләр һәм листовкалар әзерләү һәм тарату;

2) учреждение биналарында һәм территориясендә янгын куркынычсызлыгы мәгълүмати стендларын урнаштыру;

Янгынга каршы пропаганда законнар нигезендә тиешле бюджет акчалары хисабына үткәрелә.

2. Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау, халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү эшен оештыру өчен җаваплы вазыйфаи зат билгеләнә.

Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Башкарма комитеты Иске Камкаавыл җирлеге территориясендә янгынга каршы пропаганда һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү буенча чараларны төп оештыручы һәм башкаручы булып тора.

3. Янгынга каршы пропаганда һәм укыту өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә җирле бюджет акчалары, шулай ук спонсорлык ярдәме, хәйрия эшчәнлеге кысаларында җәлеп ителгән акчалар кулланыла.

4. Янгынга каршы пропаганда һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү даими нигездә һәм өзлексез үткәрелә.

5. Торак секторда һәм кешеләр күп була торган объектларда янгын-профилактика эшен оештырганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү, шул исәптән тикшерелә:

- янгын куркынычсызлыгын саклау буенча оештыру чараларын үтәү;

- территорияне, биналарны һәм бүлмәләрне карап тоту;

- эвакуация юлларының һәм чыгу урыннарының торышы;

- оешма персоналының янгын чыккан очракта гамәлләргә әзерлеге;

- гамәлдәге законнар нигезендә ирекле янгын дружинасы булу һәм җиһазланышы;

- гамәлдә булган законнар нигезендә янгын куркынычсызлыгы чараларына учреждение һәм оешма хезмәткәрләрен укыту һәм янгынга каршы пропаганда оештыру һәм үткәрү;

- күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге һәм эчке эшләр бүлеге белән ассоциатив яшәү рәвеше алып баручы затларның һәм имин булмаган гаиләләрнең яшәү урыннарының янгынга каршы торышын тикшерү буенча уртак рейдлар үткәрү.

Әлки муниципаль районы Иске Камка

авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021

елның 13 апрелендәге 8 номерлы карарына

2 нче кушымта

**Торак секторда һәм кешеләр күп була торган объектларда янгын-профилактика эшләре буенча чаралар планы**

| № | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | Учреждение җитәкчеләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү эшенә җәлеп итәргә | даими | Башкарма комитет, учреждение, предприятие җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2 | Полиция участок вәкиле белән ассоциатив яшәү рәвеше алып баручы затларга уртак рейдлар үткәрү. | квартал саен | Башкарма комитет, участок полиция инспекторы (килешү буенча) |
| 3 | Халыкны янгынга каршы режим кагыйдәләренә, янгын очрагында гамәлләргә өйрәтү буенча буклетлар тарату | даими | Башкарма комитет, учреждение, предприятие җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4 | Ялгыз, өлкән яшьтәге гражданнарны, спиртлы эчемлекләр кулланучыларны янгынга каршы режим кагыйдәләренә өйрәтүне оештырырга | квартал саен | Башкарма комитет |